| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>МАЛОБУИНКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР БУАСЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татар Буасы авылы

«13 » июль 2023 ел. № 71-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
«Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш
җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
чикләрен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татар Буасы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча 2023 елның 4 июлендә үткәрелгән гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә (үзгәрешләр кертеп, муниципаль берәмлекләр чикләренең карта-схемасы) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре үзгәрүе белән килешергә.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, басма-редакция газетасында Знамя (Байрак, Ялав), шулай ук Татар Буасы авыл җирлегенең рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырылырга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегенең мәгълүмати стендында урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе Р.Ф. Йосыпов

ТР Буа муниципаль районы Татар Буасы
авыл җирлеге Советының
2023 елның 13 июлендәге 71-2 номерлы
карарына кушымта

